**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 17 апрель № 257

г. Казань

Татарстан Республикасының кайбер социаль хезмәт күрсәтү оешмалары койка фондын билгеләү турында

Психикалары бозылудан интегүче гражданнарның стационар социаль хезмәт күрсәтүгә дәүләт тарафыннан гарантияләнгән хокукларын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елның 1 июненнән түбәндәгеләрнең койка фондын билгеләргә:

«Яңа Чүриле психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 373 койка-урын күләмендә;

«Алабуга психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 460 койка-урын күләмендә;

«Зеленодольск психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 544 койка-урын күләмендә;

«Чистай психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 286 койка-урын күләмендә;

«Казан психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 337 койка-урын күләмендә;

«Кама Аланы психоневрология интернаты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең 440 койка-урын күләмендә.

2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре койка фондын билгеләү буенча оештыру чараларын гамәлгә ашырырга.

3. Бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү өлешендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомоствосы буенча күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, бу карарны кабул итүгә бәйле рәвештә, бер ай эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\257.doc